МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

07.04.2023 Казан ш. № 02-32

“Чираттагы финанс елына һәм планда каралган чорга Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен раслау турында” 29.04.2011 ел, № 02-45 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Б о е р ы к б и р ә м:

“Чираттагы финанс елына һәм планда каралган чорга Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен раслау турында” 29.04.2011 ел, № 02-45 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгына кертелә торган үзгәрешләрне (кушымта итеп бирелә) расларга.

Министр Р.Р. Гайзатуллин

Татарстан Республикасы
Финанс министрлыгының
07.04.2023 ел № 02-32
боерыгы белән расланды

«Чираттагы финанс елына һәм планда каралган чорга Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен раслау турында» 29.04.2011 ел, № 02-45 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгына кертелә торган үзгәрешләр

1. Боерыкның преамбуласында «Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты проекты» дигән сүзләрне «Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты проекты» дигән сүзләргә алыштырырга.

2. Бу боерык белән расланган Чираттагы финанс елына һәм планда каралган чорга Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен планлаштыру тәртибендә:

1) 1 пунктта «Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты проекты» дигән сүзләрне «Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты проекты» дигән сүзләргә алыштырырга;

2) 1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Төп средстволарга капитал салулар формасында бюджет инвестицияләренә чыгымнарны планлаштыру Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына дәүләт учреждениеләренең һәм дәүләт унитар предприятиеләренең төп средстволарына капитал салулар рәвешендә бюджет инвестицияләрен һәм муниципаль милектәге капиталь төзелеш объектларын финанслашуга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә субсидияләрне күздә тотучы программаларны формалаштыру һәм тормышка ашыру һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланылучы бюджет инвестицияләрен хәл итү буенча күчеш нигезләмәләрен раслау турында тәртип нигезендә тормышка ашырыла.»;

3) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Бюджет ассигнованиеләрен планлаштыру гамәлдәге һәм кабул ителгән йөкләмәләрне үтәүгә бюджет ассигнованиеләре буенча аерым башкарыла.»;

4) 4 нче пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Бюджет һәм автономияле учреждениеләр тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүгә (эшләрне башкаруга) бюджет ассигнованиеләрен планлаштыру дәүләт йөкләмәсен, шулай ук аның хисап финанс елында һәм агымдагы финанс елында үтәлешен исәпкә алып башкарыла.»;

5) 5 пунктта «Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты проекты» дигән сүзләрне «чираттагы финанс елына һәм планда каралган чорга Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты проекты» дигән сүзләргә алыштырырга;

6) 8 пунктта:

«в» пунктчасының алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-бу Тәртипкә №17 кушымта нигезендәге форма буенча, дәүләт заданиеләре нигезендә, бюджет һәм автоном учреждениеләр тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) бюджет ассигнованиеләренең ачыкланган исәпләмәсе;»;

8 нче пунктның «е» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«е) чираттагы финанс елына һәм планда каралган чорга бюджет ассигнованиеләре нигезләмәләрендә күрсәтелгән Татарстан Республикасы дәүләт программаларын тормышка ашыруны финанс ягыннан тәэмин итүгә юнәлдерелгән бюджет ассигнованиеләреннән файдалану нәтиҗәләре күрсәткечләренең Татарстан Республикасы дәүләт программаларында күрсәтелгән күрсәткечләргә һәм дәүләт заданиеләрендә күрсәтелгән, күрсәтелгән дәүләт хезмәтләре сыйфаты һәм (яки) күләмен (эчтәлеге) күрсәткечләренә туры килүен тәэмин итә.»;

7) 11 пунктта:

«в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) тиешле баш бүлүчеләрнең чираттагы финанс елына һәм планда каралган чорга нигезләнешләрендә аларда күрсәтелгән, Татарстан Республикасы дәүләт программаларын һәм дәүләт заданиеләрен тормышка ашыруны финанс ягыннан тәэмин итүгә юнәлдерелгән бюджет ассигнованиеләреннән файдалану нәтиҗәләре күрсәткечләренең Татарстан Республикасы дәүләт программаларында күрсәтелгән күрсәткечләргә һәм дәүләт заданиеләрендә күрсәтелгән, күрсәтелгән дәүләт хезмәтләре сыйфаты һәм (яки) күләмен (эчтәлеге) күрсәткечләренә туры килүен тикшерә;»;

«г» пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

8) 12 пунктта:

«а» пунктчасында «Татарстан Республикасы Президентының норматив-хокукый актлары» дигән сүзләрне «Татарстан Республикасы Рәисенең норматив- хокукый актлары» дигән сүзләргә алыштырырга;

«в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) планлы ысул – Татарстан Республикасы дәүләт программаларына кертелмәгән Татарстан Республикасы дәүләт милке объектларына бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыруны күздә тоткан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив-хокукый актында (килешүдә) күрсәтелгән күрсәткечләргә туры китереп, бюджет ассигнованиесе күләмен билгеләү;»;

9) 13 нче пунктның беренче абзацында «акчалата тәэмин итү» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

10) 15 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуга бюджет ассигнованиеләре күләме исәпләнелә:»;

«б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтүнең производство циклы вакыты расланылган бюджет йөкләмәләре лимитларының гамәлдә булу срогыннан арткан эшләр башкаруны, хезмәтләр күрсәтүне күздә тоткан дәүләт контрактларын тормышка ашыруга бюджет ассигнованиеләре өчен – планлы ысул белән, һәм алар әлеге дәүләт контрактлары нигезендә күрсәтелә.»;

11) 17 нче пунктта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актлары» дигән сүзләрдән соң «бюджет акчаларын баш бүлүченең актлары,» дигән сүзләрне өстәргә;

12) 18 пунктта «расланган озак сроклы (республика максатчан программаларын, шулай ук инвестиция проектларын) гамәлгә ашыруга» дигән сүзләрне «Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә» дигән сүзләр белән алыштырырга;

13) 19 нчы пунктның икенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

14) 20 пунктның «б» пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

15) 21 пунктның «а» пунктчасында «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары» дигән сүзләрне «башка норматив хокукый актлар» дигән сүзләргә алыштырырга;

16) 22 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«22. Дәүләт (муниципаль) милектәге объектларга бюджет инвестицияләрен хәл итүгә һәм дәүләт яки муниципаль учреждениеләр һәм дәүләт яки муниципаль унитар предприятиеләр булып тормаучы юридик

затларга бюджет инвестицияләрен хәл итүгә кабул ителүче йөкләмәләрне үтәүгә бюджет ассигнованиеләре күләмнәре (Россия Федерациясе Бюджет кодексының 79 һәм 80 статьялары) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив-хокукый актлары нигезендә, планлы ысул белән исәпләнелә.»;

17) 23 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«23. Җирле бюджетлардан бирелә торган, муниципаль милек объектларына капитал салуларны финанслашуга җирле бюджетларга субсидияләр күләмнәре (Россия Федерациясе Бюджет кодексының $79^1$ статьясы) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив-хокукый актлары нигезендә, планлы ысул белән исәпләнелә.»;

18) 26 нчы пунктның беренче абзацында «акчалата тәэмин итү,» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

19) 28 нче пунктта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актлары» дигән сүзләрдән соң «бюджет акчаларын баш бүлүченең актлары белән,» дигән сүзләрне өстәргә;

20) 29 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«29. Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә бюджет ассигнованиеләре күләме планлы ысул белән исәпләнә һәм Татарстан Республикасы дәүләт программалары паспортлары нигезендә күрсәтелә.»;

21) 31 пунктта «Татарстан Республикасы норматив-хокукый актлары белән» дигән сүзләрне «башка норматив-хокукый актлар белән» дигән сүзләргә алыштырырга;

22) 32 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«32. Дәүләт (муниципаль) милектәге объектларга бюджет инвестицияләрен хәл итүгә һәм дәүләт яки муниципаль учреждениеләр һәм дәүләт яки муниципаль унитар предприятиеләр булып тормаучы юридик затларга бюджет инвестицияләрен хәл итүгә кабул ителүче йөкләмәләрне үтәүгә бюджет ассигнованиеләре күләмнәре (Россия Федерациясе Бюджет кодексының 79 һәм 80 статьялары) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив-хокукый актлары нигезендә, планлы ысул белән исәпләнелә.»;

23) 33 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«33. Муниципаль милектәге объектларга капитал салуларны финанслашуга җирле бюджетларга субсидияләр бирү буенча кабул ителүче йөкләмәләрне үтәүгә җирле бюджетлардан хәл ителүче бюджет

ассигнованиеләре күләмнәре (Россия Федерациясе Бюджет кодексының 79[1] статьясы), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив-хокукый актлары нигезендә, планлы ысул белән исәпләнелә.»;

24) 41 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«41. Мәгълүматларның 2 графасында (№3 кушымта) Татарстан Респу бликасы бюдж еты средстволарын баш бүлүче коды чагылдырыла.»;

25) 47.2 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Чираттагы финанс елына һәм планда каралган чорга нигезләнешләрдә күрсәтелгән Татарстан Республикасы дәүләт программаларын һәм дәүләт заданиеләрен тормышка ашыруны финанс ягыннан тәэмин итүгә юнәлдерелгән бюджет ассигнованиеләреннән файдалану күрсәткечләренең Татарстан Республикасы дәүләт программаларында күрсәтелгән күрсәткечләргә һәм дәүләт заданиеләрендә күрсәтелгән, күрсәтелгән дәүләт хезмәтләре сыйфаты һәм (яки) күләме (эчтәлеге) күрсәткечләренә туры килүе.»;

26) 49 пунктта «Татарстан Республикасы Президентының» дигән сүзләрне «Татарстан Республикасы Рәисенең» дигән сүзләргә алыштырырга;

27) 52 пунктта «Татарстан Республикасы Президентының” дигән сүзләрне «Татарстан Республикасы Рәисенең» дигән сүзләргә алыштырырга;

28) 53 пунктта «Татарстан Республикасы законнары, норматив-хокукый акт абзацларын» дигән сүзләрне, «Татарстан Республикасы законнары, башка норматив-хокукый акт абзацларын» дигән сүзләргә, «Татарстан Республикасы законы, норматив-хокукый акты булып тора» дигән сүзләрне «Татарстан Республикасы законы, башка норматив-хокукый акты булып тора» дигән сүзләргә алыштырырга;

29) 54 пунктта «норматив-хокукый актының» дигән сүзләрне «башка норматив-хокукый актының» дигән сүзләргә алыштырырга;

30) 55 пунктта «норматив-хокукый актының» дигән сүзләрне «башка норматив-хокукый актының» дигән сүзләргә алыштырырга;

31) 61 пунктта «Татарстан Республикасы Президентының» дигән сүзләрне «Татарстан Республикасы Рәисенең» дигән сүзләргә алыштырырга;

32) 64 пунктта «Татарстан Республикасы Президентының» дигән сүзләрне «Татарстан Республикасы Рәисенең» дигән сүзләргә алыштырырга;

33) 65 пунктта «Татарстан Республикасы законнары, норматив-хокукый акт абзацларын» дигән сүзләрне, «Татарстан Республикасы законнары, башка норматив-хокукый акт абзацларын» дигән сүзләргә, «Татарстан Республикасы законы, норматив-хокукый акты булып тора» дигән сүзләрне «Татарстан

Республикасы законы, башка норматив-хокукый акты булып тора» дигән сүзләргә алыштырырга;

34) 66 пунктта «норматив-хокукый актының» дигән сүзләрне «башка норматив-хокукый актының» дигән сүзләргә алыштырырга;

35) 74 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«74. Татарстан Республикасы бюджеты средстволарын Баш бүлүче һәм аның карамагындагы бүлүчеләр һәм алучылар тарафыннан күрсәтеләүче дәүләт хезмәте сыйфатын билгеләү мөмкинлеге булганда, күрсәтелүче дәүләт хезмәте күләмен (эчтәлеген) билгеләүче турыдан-туры нәтиҗәләр күрсәткеченнән тыш, күрсәтелүче дәүләт хезмәте сыйфатын билгеләүче күрсәткеч күрсәтелә.»;

36) 77 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«77. Татарстан Республикасы дәүләт программаларын тормышка ашыруны финанс ягыннан тәэмин итүгә юнәлдерелгән бюджет ассигнованиеләре өчен Татарстан Республикасы дәүләт программаларының турыдан-туры нәтиҗәләре күрсәткечләре күрсәтелә.»;

37) 78 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

38) 85 – 88 пунктларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

39) 89 пунктта «8 графада» дигән сүзләрне «7 графада» дигән сүзләргә алыштырырга;

40) №3 кушымтаның «Бюджет ассигнованиеләренең башлангыч исемлеген аныклау буенча мәгълүматлар» таблицасының 2 графасында «ППП буенча» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

41) № 14 кушымтаның «Ахыргы нәтиҗәләр турында мәгълүматлар» 6 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Ахыргы нәтиҗәләр турында мәгълүматлар

| Күрсәткеч атамасы | Юл коды | Үлчәү берәмлеге атамасы | Хисап финанс елы | Планда каралган чорның II елы | Үзгәреш (гр. 5 - гр. 4) | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | 01». | | | | | |